Татарстанда туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы уңаеннан, 5-6нчы сыйныф укучылары белән татар шагыйрьләре исемнәре белән аталган авыл урамнарын барлап, проект эше башкардык. Укучыларыбыз урамнарны фотоларга төшереп, алар ни өчен шушы шагыйрь исемен йөртүләре турында мәгълүмат тупладылар.




